**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

"31" января 2024г. № 16

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 880 номерлы «Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 558-Фз номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 880 номерлы «Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында» карарына (26.08.2022 № 159, 14.11.2022 № 244 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибенә:

А) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлекнең әлеге тәртибе расланган җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган эшчәнлек төрләре исемлеге:

а) Медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

б) Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә ярдәм итү;

в) Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда социаль хезмәтләр күрсәтүгә ярдәм;

г) Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауда ярдәм, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү.»;

Б) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Җирле үзидарә органнары «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган рәвешләрдә ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм күрсәтә.

15.1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм түбәндәге рәвешләрдә күрсәтелергә мөмкин:

1) финанс ярдәме, шул исәптән грантлар һәм субсидияләр бирү;

2) оештыру ярдәме;

3) мәгълүмати ярдәм;

4) консультация ярдәме;

5) мөлкәти ярдәм, шул исәптән биналарны түләүсез файдалануга бирү;

6) методик ярдәм.

15.2. Ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеге, 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль законның 17.4 статьясындагы 2 пунктында каралган формаларны исәпкә алып, җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән ярдәм чаралары турында мәгълүмат ихтыярый ярдәм (волонтерлык) үсеше өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль законның 17.5 статьясындагы 2 пунктында каралган тәртип нигезендә урнаштырыла.

15.3. Коммерция оешмалары булган ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Житәкче И.Х. Хәмидуллин